**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**Сарманавылжирлеге**
**423350 Сарманавылы, М.Жэлилур., 63**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E - mail: Sar.sar @ tatar.ru**
ИНН/КПП 1636001266/163601001

**Сармановское сельское поселение**
**САРМАНОВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**423350 с. Сарманово, ул.М.Джалиля, 63**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E – mail: Sar.sar @ tatar.ru**
ИНН/КПП 1636001266/163601001

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**20.03.2024 г.** **№ 1**

«Сарман авыл җирлеге Яңа Әхмәт торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 19 октябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 19 октябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясына туры китереп, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР ИТӘ:**

1. 2024 елның 30 мартында 13.00 сәгатькә Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Яңа Әхмәт торак пункты, Ленин урамы, 9 йорт адресы буенча урнашкан Яңа Әхмәт авылы клубы бинасында «Сарман авыл җирлеге Яңа Әхмәт торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 19 октябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 19 октябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар жыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сарман авыл җирлеге Яңа Әхмәт торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 19 октябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 19 октябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

1) Торак пункт территориясен төзекләндерү (Яңа Әхмәт торак пунктында су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итүче инженерлык корылмалары төзү (су алу җайланмасы будкасы өчен төзелеш материаллары сатып алу);

2) Һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары түгел (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре)) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Яңа Әхмәт торак пунктында һәйкәлне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары түгел (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре)) һәм авыл клубы бинасы янындагы территорияне төзекләндерү.)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Сарман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка чыгарырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://https://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы
Сарман авыл җирлеге башлыгы Ф.М.Хөснуллин